**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
20 нче май 2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№45-01

2024 елга Актаныш муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында

Актаныш муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе А.А.Корбангалинаның 2024 елга Актаныш муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы бюджетының 2024 елга үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 1 620 997,2 мең сум күләмендә, төгәлләштерелгән план буенча 1 644 197,4 мең сум, чыгымнар буенча 1 668 406,7 мең сум, төгәлләштерелгән план буенча 1 697 331,8 мең, дефицит белән 47 409,5 сум, дефицит белән төгәлләштерелгән план буенча 53 134,4 мең сум күләмендә расларга;
2. 2024 елга Актаныш муниципаль районы бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын 1 нче кушымта нигезендә расларга;
3. 2024 елга Актаныш муниципаль районы бюджетының фаразланган керемнәре күләмнәрен 2 нче кушымта нигезендә расларга;
4. 2024 елга Актаныш муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын 3 нче кушымта нигезендә расларга;
5. 2024 елга Актаныш муниципаль районы бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне 4 нче кушымта нигезендә расларга;
6. «2024 елга Актаныш муниципаль районы бюджеты чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары, чыгымнар төрләре, бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү»не 5 нче кушымта нигезендә расларга;
7. 2024 елга Актаныш муниципаль районының муниципальара характердагы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә җирлекләр бюджетларыннан субсидияләрне 6 нчы кушымта нигезендә расларга.;
8. 2024 елга «Актаныш муниципаль районы бюджетыннан җирлекләргә дотацияләр күләмен» 7 нче кушымта нигезендә расларга;
9. 2024 елга «Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны» 8 нче кушымта нигезендә расларга;
10. Әлеге карар Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырылып чыгарылырга тиеш.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе

Л.Р.Зарипов